**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь, 2025 ел № 1001-п

2026 елның I кварталына Питрәч муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «2026-2027 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Питрәч муниципаль районында «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгы тарафыннан торак урыннарның 1 квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренү нәтиҗәләренә ярашлы рәвештә (Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлегенең коммерцияле булмаган партнерлыгының 2025 елның 5 сентябрендәге 292 нче номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» хаты), Питрәч муниципаль районы буенча торак урынының гомуми мәйданының 1 квадрат метры бәясен яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә 2026 елның I кварталына индивидуаль торак йорт төзү өчен социаль түләү күләмен исәпләп чыгару өчен 105423,50 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов